КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 август г.Казань № 800

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2021 ел, 3 март, 116 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2021 ел, 3 март, 116 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 сентябрь, 865 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «44 542» саннарын «42 936» саннарына алмаштырырга;

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлегендә түбәндәге эчтәлекле юлны төшереп калдырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «16:33:080702:2 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Званка авылы, Зеленая ур., 26 нчы җир кишәрлеге | 1 606 | «Данафлекс» ябык акционерлык җәмгыяте; |

«Барлыгы» юлында «44 542» саннарын «42 936» саннарына алмаштырырга;

16:33:080702:2 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 1 606 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин